ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27 апрель, 2018 ел № 24/6

Даими рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүче затларның хезмәтенә түләү системасы турында

Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2009 елның 12 февралендәге «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайлаулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен башкару гарантияләре турындагы» 15-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте Кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2018 елның 28 мартындагы "Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" 182 санлы Карары, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1.Расларга:

1) даими рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең һәм Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүче затларның хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларын 1 нче кушымтага

нигезләнеп;

2) шәһәр Хакимен, муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасарын, Контроль-хисап палатасы Рәисен акчалата бүләкләү күләмнәрен 2 нче кушымтага нигезләнеп;

3) муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмен исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлау коэффициентларын һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмен 3 нче кушымтага нигезләнеп;

2. Билгеләргә:

1) муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи хезмәт хаклары күләме11163 сумнан чыгып исәпләнә;

2) әлеге Карар белән муниципаль хезмәткәрләргә билгеләнгән хезмәт хакының еллык күләме 2018 елның 31 мартына кадәрге хезмәт хакының еллык күләменнән ким булмаска тиеш;

3) муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи хезмәт хаклары күләме, шулай ук айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләме бер сумга кадәр түгәрәкләндерелеп, арттыру ягына хисаплана.

3. Гамәлдән чыккан дип танырга:

1) Шәһәр Советының 2007 елның 25 декабрендәге «Яр Чаллы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында» 28/7 санлы Карарын, «Челнинские известия» гасзетасының 2008 ел, 11 гыйнвардагы 6-8 саннарында бастырылган;

2) Шәһәр Советының 2008 елның 23 гыйнварындагы «Шәһәр Советының 2007 елның 25 декабрендәге «Яр Чаллы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында»28/7 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 29/7 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2008 ел, 01 февральдәге 21-23 саннарында бастырылган;

3) Шәһәр Советының 2008 елның 23 гыйнварындагы «Муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладына айлык өстәлмә һәм класс чины өчен муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладына айлык өстәлмә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезнамәне раслау хакында» 29/8 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2008 ел, 01 февральдәге 21-23 саннарында бастырылган;

4) Шәһәр Советының 2008 елның 16 июлендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең вазыйфаи окладын билгеләү турында» 33/8 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2008 ел, 25 июльдәге143-145 саннарында бастырылган;

5) Шәһәр Советының 2008 елның 25 сентябрендәге «Шәһәр Советының 2007 елның 25 декабрендәге «Яр Чаллы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында»28/7 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 34/16 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2008 ел, 08 октябрьдәге № 195-196 саннарында

бастырылган;

6) Шәһәр Советының 2009 елның 09 апрелендәге Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча Шәһәр Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 40/23 санлы Карарының 4 нче, 5нче пунктларын;

7) Шәһәр Советының 2009 елның 09 апрелендәге «Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү вазифаларын башкаручы затларның һәм Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарында эшләүче җиңел автомобильль йөртүчеләрнең хезмәтләренә түләү тәртибә турындагы Нигезнамә хакында» 40/25 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2009 ел, 17 апрельдәге 73-75 саннарында бастырылган;

8) Шәһәр Советының 2009 елның 22 октябрендәге «Даими рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның хезмәтенә түләү хакында» 43/17 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2009 ел, 05 ноябрьдәге 212-214 саннарында бастырылган;

9) Шәһәр Советының 2010 елның 31 мартындагы «Муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладына айлык өстәлмә һәм класс чины өчен муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладына айлык өстәлмә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы» Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 47/9 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2010 ел, 05 майдагы 82-83 саннарында бастырылган;

10) Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы «Муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең һәм җирле үзидарә органнарының эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү вазифаларында эшләүче затларның хезмәтләренә түләү өлкәсендә Шәһәр Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 13/7 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2011 ел, 02 сентябрьдәге 94 санынында бастырылган;

11) Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча Шәһәр Советының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү турында» 21/11 санлы Карарының 3 нче пунктын;

12) Шәһәр Советының 2012 елның 20 декабрендәге «Шәһәр Советының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү турында» 22/9 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2012 ел, 28 декабрьдәге 101 санында бастырылган;

13) Шәһәр Советының 2012 елның 20 декабрендәге «Шәһәр Советының 2009 елның 09 апрелендәге 40/25 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү вазифаларын башкаручы затларның һәм Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарында эшләүче җиңел автомобильль йөртүчеләрнең хезмәтләренә түләү тәртибә турындагы Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында», 22/10 санлы Карарын,

«Челнинские известия» газетасының 2012 ел, 28 декабрьдәге 101 санында бастырылган;

14) Шәһәр Советының 2012 елның 20 декабрендәге «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасы» МКУ оештыру һәм эшчәнлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча Шәһәр Советының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү турында»22/13 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының» 2012 ел, 28 декабрьдәге 101 санында бастырылган;

15) Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча Шәһәр Советының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү турында» 26/15 санлы Карарының 6 нчы,7 нче пунктларын;

16) Шәһәр Советының 2013 елның 31 октябрендәге 27/8 санлы Карарын «Шәһәр Советының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү турында», «Челнинские известия» газетасының 2013 ел, 15 нобрьдәге 86 санында бастырылган;

17) Шәһәр Советының 2013 елның 31 октябрендәге «Шәһәр Советының 2009 елның 9 апрелендәге 40/25 санлы Карары белән расланган җирле үзидарә эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү вазифаларын башкаручы затларның һәм Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарында эшләүче җиңел автомобиль йөртүчеләрнең хезмәтләренә түләү тәртибе хакында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү турында» 27/11 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2013 ел, 20 ноябрьдәге 87 санында бастырылган

18) Шәһәр Советының 2013 елның 19 декабрендәге «Хезмәткә түләү өлкәсендә Шәһәр Советының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү турында»28/8 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2013 ел, 27 декабрьдәге 98 санында бастырылган;

19) Шәһәр Советының 2017 елның 19 сентябрендәге «Шәһәр Советының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү турында»19/6 санлы Карарын, «Челнинские известия» газетасының 2017ел, 27 сентябрьдәге 71 санында бастырылган;

4. Әлеге Карар 2018 елның 01 апреленнән соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев